Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
«Ульяновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлегенең Саминовка авылы торак пунктында

27 октябрь 2023 ел № 2/2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Саминовка авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Ульяновка авыл җирлегенең Саминовка авылы территориясендә теркәлгән һәм дәими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәгеләрдән һәм 90 яшьтән өлкәнрәк булган гражданнардан тыш.

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Саминовка торак пунктында урам утларын монтажлауга, урнаштыруга, ремонтлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, урам утларын куллану чыгымнарын түләүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- Саминовка торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнарына;

- Ульяновка, Сосновка, Девичья Поляна торак пунктларында су башнялары, скважиналар территорияләрен төзекләндерү, электр энергиясе һәм хезмәт күрсәтүләр өчен чыгымнарны түләү, кирәкле материаллар һәм инструментлар алу;

- Ульяновка авыл җирлегендә урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу: вак таш сатып алу, фракция 20-30 мм.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге башлыгы С.З. Шәмсетдинов